Яшел Үзән муниципаль районы

«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 5 нче гимназиясе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе.

# “Туган ягым – яшел бишек” проекты

Үтәүче: 8А сыйныф укучысы
Богданов Таһир
Җитәкчесе : Сәләхова З.Ү, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Мин атаклы Шырдан авылы егете. Ата- бабаларым нигез салып калдырган җирдә яшим.Шырдан таулар итәгенә сыенып, урманнар күләгәсендә гомер кичерә. Хезмәт сөючән халкы тырышлыгы белән ул көннән - көн матурлана, үсә. Атаклы ”Шырдан катыгы” аның данын ерак-еракларга тарата, бик күпләр бу катыкны эзләп, дистә чакрым юллар үтеп, безнең якларга килеп чыга, аның асылына төшергә омтыла, серен ачарга тели. “Тик бу юкка ”, - ди әнием,- аның бөтен сере суларга, чишмәләргә барып тоташа. Никадәр генә тырышсаң да, “Шырдан катыгы”ның игезәген ясап булмый,”- дип аңлата. Бәлки бу чыннан да шулайдыр, дип мин авылым гидронимнарының тарихын өйрәнергә керештем, укый-эзләнә торгач, бик кызыклы мәгълүматка тап булдым: күренекле якташыбыз Каюм Насыйри безнең авылны “Җиде чишмә авылы” дип, ул заманда ук халыкка шифалы суларын бүләк итүче җиде чишмәне -Таш инеш, Чирмеш, Чәй суы, Бадыйган, Көтүче , Каюм, Җәбәрчән чишмәләрен атаган.



Чәй суы

Танышуны Каюм абый үз куллары белән казып калдырган Каюм кизләвеннән башлыйк. Галим безнең авылга туганнарына кунакка килгәч, урман – күлләр, тау буйларында йөрергә яраткан, шушындый бер сәфәре вакытында ул чокыр төбеннән су сыркып торуын күреп алган һәм икенче көнне туганнары ярдәме белән шушы чишмәне казып чыгарганнар. Авылдашларым олы хөрмәт

белән бу чишмәне Каюм кизләве дип атый. Ул чисталыгы һәм татлы суы белән дан тота.



Каюм кизләве

Ә менә Бадыйган чишмәсе иң изге чишмәләрнең берсе санала, хәтта аның өстеннән атлап чыгарга ярамый. Бадыйган чишмәсенең атамасы да, Каюм кизләве кебек үк, шәхес исеме белән бәйле. Безнең авылга кайтып урнашкан Бадыйган бай чокыр буенда йорт төзеткән, кышлар үтеп, язлар җиткәч, шушы чокыр төбендә челтерәп аккан суны күреп алган. Кызыксынып чокыр буйлап өскә таба менгәч, үзе дә сизмәстән, чишмәгә барып чыккан ул. Бадыйган чишмәне яңарткан, чистарткан, күренеп торсын дип, янына тал агачы утырткан. Әлеге тал хәзер дә һәр язны яшәрә, беркемнең дә аны кисәргә кулы бармый.



Бадыйган чишмәсе



Бадыйган чишмәсе күле

Суының салкынлыгы ягыннан беренчелек – Чирмеш чишмәсендә икән. Бик күптән аның тирәсенә чирмешләр килеп урнашкан, тик алар авыл халкы белән уртак тел таба алмаганар, авыл халкы аларны куып җибәргән, ә менә чишмә алар

исемен алып



калган.

Чирмеш чишмәсе

Халыкта Кабак тавыннан агучы Көтүче чишмәсенең  суындагы шифа турында сүзләр күп йөри. Ул көньякка карап агучы бердәнбер чишмә. Авыр хаста белән көрәшеп, түшәктә яткан кешеләр, бу чишмәнең бер тамчы суын эчсәләр дә, терелеп булачагына ышанганнар, чөнки моны раслаучы хәлләр еш булган. Кабак тавының тарихы да - күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итәрдәй тарих. Әлеге кырда “Кабак” ягы ял итү урыны урнашкан булган. Безнең авылдан  ерак түгел “Екатеринка”—Екатерина II вакытыннан калган

“ Мәскәү-Себер”, соңрак  Никалай II  төзеткән тимер юлы үтә. Шушы юл аша йөргән кешеләр “кабак” та ял итә торган булганнар.



Көтүче чишмәсе

А. С. Пушкин “ Капитанская дочка” әсәрен язганда, шушы юл белән Казанга килгән. Безнең яктагы “ Пугачев восстаниесе” шаһидлары белән аралашкан. Зөя утравы аркылы Казанга юл тоткан.



Кабак тавы

Таш инеш - элек-электән җентекләп ясалган инеш. Инешнең төбенә тулысынча таш җәелгән һәм шунлыктан ул үзенә күрә кечкенә бер күлне хәтерләтә. Күлнең кырыйлары тулысынча киртә белән уратып алынган. Инеш улактан агып чыга.

Әлеге инешнең улагы авылда иң озын улак булып санала. Аның өчен агачны җентекләп сайлап алалар, һәм бу эшне бары тик иң тәҗрибәле балта остасы гына башкара. Әлеге инеш буенда, борынгыдан килгән гадәт буенча, иң мөһим вакыйгалар - каз өмәсе, кич утыру оештырыла. Авылга яңа төшкән яшь киленнәр беренче тапкыр чәй суына шушы чишмәгә бара.



Таш инеш

Җәбәрчән күле таулы урында урнашкан. Элек - электән иң зур күлләрнеңберсе булып саналган. Күл җир асты чишмәләреннән барлыкка килгән. Халыкта шундый риваять йөри. Безнең авылга иң беренче килеп урнашучы кешеләрне башлыгы бик бай кеше булган. Аның чибәр кызы, ни сәбәпледер, атасы белән гаугага чыгып (талашып), шушы күлгә батып үлә. Атасы ничек, диеп сорагач, кешеләр җәбер - җебер килде, дигәннәр.



Җәбәрчән күле

Җәбәрчән күле хәзер дә  сугыш хатирәләрен саклый, окоп урыннары аерым- ачык күренеп тора. Казу эшләре вакытында эзтабарлар бу окоплардан бик күп сугыш кораллары, солдат флягалары табып



алганнар.





Бу мәгълүматләрне кайдан алган дип гаҗәпләнәсездер. Әлеге фотосүрәттә борынгы истәлек дәфтәре. Ул безгә дәү әниебездән мирас булып калды. Дәү

әнинең олы кызы аны кирилицага тәрҗемә иткән.



Истәлек дәфтәре.

Бу минем эзләнүләремнең башлангычы гына. Киләчәктә шушы шөгылемне дәвам итмәкче булам. Чөнки, авылым чишмәләре тарихын белү, минем өчен зур байлык.Үзем туып үскән Шырдан авылы чишмә - күлләренең һәм дә елгаларының тарихын өйрәнеп, үземнән соң киләчәк буынга туплап калдырырга телим. Энҗе – мәрҗәннәрдән дә кыйммәтле байлык бит бу!